РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643 село Камаево, ул.Дифгата Сирая
д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел.(885549)3-55-33 ИНН 1627001164, КПП162701001 ОГРН 1021601118043

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

2020 елның 21 нче декабреннән № 15

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата бүләкләү, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 6.08.2020 ел, № 658 "Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендәге 72 номерлы «Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында " карары белән расланган муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга .

2. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендәге 72 номерлы «Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында " карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең биләгән вазыйфалары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен арттырырга .

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм www.mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Совет Рәисе
Камай авыл җирлеге башлыгы И.И. Әһлиева